ГЛАВА САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2024 с. Сарманово №156

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры нигезендә карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны 2024 елның 12 октябренә билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Янурыс авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга. Адресы: Татарстан Республикасы Сарман районы, Сарман районы, Янурыс авылы, Ленин ур., 43а, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советының утырышлар залы.
4. Язма рәвештә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгышлар хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Сарман муниципаль районы, Сарман авылы, Ленин урамы, 35 (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә